ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**31.01.2023**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 149**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге 2685 номерлы карары белән расланган ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең үзара эшчәнлеге тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Хәйрия эшчәнлеге һәм ирекләлек (волонтерлык) турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 7 октябрендәге 394-ФЗ номерлы Федераль закон, «Хәйрия эшчәнлеге һәм ихтыярый (волонтерлык) турында» 1995 елның 11 августындагы 135-ФЗ номерлы Федераль закон, «Ирекләлек (волонтерлык) өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 30 июнендәге 48-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 20 декабрендәге 2685 номерлы карары белән расланган, ирекле (волонтерлык) эшчәнлекне оештыручылар, ирекле (волонтерлык) оешмалары белән җирле үзидарә органнарының һәм муниципаль учреждениеләрнең үзара хезмәттәшлеге тәртибенә (алга таба - Тәртип) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 3 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«медицина ярдәме күрсәтә торган оешмаларда медицина ярдәме күрсәтүдә ярдәм итү»;

«Россия Федерациясе законнары нигезендә җәмәгать тәртибен саклауда эчке эшләр органнарына (полициягә) һәм башка хокук саклау органнарына ярдәм итү»;

«хәбәрсез югалган затларны эзләүдә гражданнарның катнашуы»;

1.2. Тәртипнең 3 пунктының дүртенче абзацында «күрсәтүдә» сүзен «гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетерүдә, янгыннарны профилактикалауда һәм сүндерүдә, һәлакәттән коткару эшләрен уздыруда, шулай ук күрсәтүдә» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тортны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Д.В. Лулаковка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин